ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.10.2021 с.Старое Дрожжаное № 432

«2015-2024 елларга Чүпрәле муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «2021-2024 елларга коррупциягә каршы тору милли планы турында» 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указының 3 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2015-2024 елга Чүпрәле муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 ноябрендәге 798 номерлы карарына (2016 елның 23 маендагы 290, 31.08.2018 № 488, 27.12.2018 № 518, 06.09.2019 № 390, 28.07.2020, 09.08.2021 № 324 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле **1.32 - 1.33** юлларын өстәргә:

«1.32. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуына мониторинг үткәрү.

1.33. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында каралган чараларны үткәрүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру, коррупцияне кисәтү, шул исәптән җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар мәнфәгатьләре конфликтын ачыклау, булдырмау һәм җайга салу буенча.»;

2) түбәндәге эчтәлекле **4.30 юлын** өстәргә:

«4.30. Муниципаль хезмәткәрләрнең, вазыйфаи бурычларына муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны уздыруда катнашу керә торган хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тору өлкәсендә ел саен квалификация күтәрүне тәэмин итү».

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет челтәрендә урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: Д.А. Сатдинов